КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 14 март г.Казань № 245

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы эшчәнлеге кысаларында Татарстан Республикасы гражданнары, дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары электрон хезмәттәшлеге турында» 2012 ел, 10 август, 676 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы эшчәнлеге кысаларында Татарстан Республикасы гражданнары, дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары электрон хезмәттәшлеге турында» 2012 ел, 10 август, 676 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 29 июль, 528 нче; 2013 ел, 5 август, 548 нче; 2014 ел, 15 март, 156 нчы; 2014 ел, 29 ноябрь, 929 нчы; 2015 ел, 30 апрель, 308 нче; 2015 ел, 2 сентябрь, 632 нче; 2015 ел, 30 октябрь, 815 нче; 2016 ел, 12 октябрь, 741 нче; 2016 ел, 31 октябрь, 802 нче; 2017 ел, 20 июнь, 394 нче; 2017 ел, 2 ноябрь, 839 нчы; 2018 ел, 12 сентябрь, 771 нче; 2019 ел, 22 март, 207 нче; 2020 ел, 30 май, 441 нче; 2020 ел, 14 декабрь, 1135 нче; 2021 ел, 19 июль, 590 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт

мәгълүмат системасы эшчәнлеге кысаларында Татарстан Республикасы гражданнары, дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары электрон хезмәттәшлеге турындагы нигезләмәдә:

2 бүлекнең унынчы абзацында «Татарстан Республикасы Мәгълүмат технологияләре үзәге» дәүләт унитар предприятиесенең гражданнарның аудио һәм видеомөрәҗәгатьләрен эшкәртү үзәге» сүзләрен «Татарстан Республикасы Цифрлы трансформация үзәге» дәүләт казна учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

3.1.2 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Халык контроле» системасының хәбәрнамәләр юнәлешләре һәм категорияләре исемлегенә туры килә торган хәбәрнамә юнәлеше һәм категориясе;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Коммуналь хезмәтләр», «Йортның агымдагы ремонты», «Йортны карап тоту» категорияләре өчен – торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә исәпләү һәм түләү өчен фатирга кереп торучыга бирелгән шәхси счет номеры; Файдаланучының фамилиясе, исеме, атасының исеме;»;

31.5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Коммуналь хезмәтләр», «Йортның агымдагы ремонты», «Йортны карап тоту», «Экстремизм, дини һәм милли җирлектәге низаглар», «Алкогольле һәм (яки) спиртлы продукция сату кагыйдәләрен бозу», «Этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне законсыз җитештерү һәм (яки) аларның әйләнеше (ваклап сатудан тыш)», «Су биологик ресурсларын законсыз аулау (тоту)», «Хезмәт, шул исәптән чакыру буенча хәрби хезмәттән азат ителгән гражданнар», «Федераль бюджет акчасы исәбеннән инвалидка (инвалид балага) бирелә торган тернәкләндерүнең техник чаралар һәм тернәкләндерү хезмәтләре», «Эшсезләргә пособиеләр» ктегорияләре һәм «Коррупциягә каршы тору» юнәлеше буенча хәбәрнамәләр Порталда, хәбәрнамәгә бирелгән статусына бәйсез рәвештә, бастырып чыгарылмый.»;

3.4.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.4. «Халык контроле» системасында хәбәрнамәне карап тикшерүнең гомуми срогы 10 календарь көннән, «Коммуналь хезмәтләр», «Йортның агымдагы ремонты», «Йортны карап тоту» категорияләре өчен өч календарь көннән арта алмый.»;

әлеге карар белән расланган «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасының хәбәрнамәләр юнәлешләре, категорияләре исемнәре һәм категорияләр модераторлары исемлегендә:

3 пунктта «Дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге (килешү буенча)» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге (килешү буенча)» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта «Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге (килешү буенча)» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге (килешү буенча)» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «14. | Төзекләндерү һәм инфраструктура | территорияне комплекслы төзекләндерү | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | күпфатирлы йортның йорт янындагы территорияләрен, шулай ук ачык участоклардагы җәмәгать урыннарын төзекләндерүне оештыру буенча тәкъдимнәр |
| | | күпфатирлы йортның йорт янындагы территориясенең асфальт түшәмәсен ремонтлау | | күпфатирлы йортның йорт янындагы территориясенең асфальт түшәмәсен ремонтлау буенча тәкъдимнәр |
| | | парклар һәм скверлар | | парклар һәм скверларны төзекләндерү, карап тоту һәм эшләвен тәэмин итү буенча тәкъдимнәр |
| | | торак төзелеше | | торак төзелешенә кагылышлы мәсьәләләр |
| | | күпфатирлы йортның йорт янындагы территориясе тротуарына, газонына кирәккә комачаулый торган киртәләр кую | | күпфатирлы йортның йорт янындагы территориясе тротуарына, газонына кирәккә комачаулый торган киртәләр кую буенча тәкъдимнәр |
| | | балалар мәйданчыгын төзекләндерү яки модернизацияләү | | балалар мәйданчыгын төзекләндерү яки модернизацияләү буенча тәкъдимнәр |
| | | урам яктырткычын оештыру | | урамнар, ишегаллар, парклар, скверларның урам яктырткычын оештыру мәсьәләләре |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | канализация люкларын карап тоту | | канализация люкларын карап тоту |
| | | йортсыз хайваннар | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе | Татарстан Республикасының торак пунктлары территориясендә йортсыз хайваннар (этләр һәм мәчеләр) булу. |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин